| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

«27» 11 2020 ел Болгар ш. № 665

«Спас муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 894 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Федераль дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашырганда үтәлүе бәяләнә торган мәҗбүри таләпләр булган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 08 октябрендәге 1631 номерлы карары нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Спас муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 894 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2.6 пунктындагы 2 абзацында «Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2013 елның 15 маендагы 26 номерлы карары нигезендә кабул ителә торган «Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының эш режимын оештыруга, эчтәлегенә һәм оештыруга санитар эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.4.1.3049-13 раслау турында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин